ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН
https://www.vatantat.ru/index.php?pg=870

# Ничекләр эш табасы?

**(“Ватаным Татарстан”, Фәния Арсланова / № 56, 19.04.2017/)**

**Эшсез калган кеше иң беренче булып мәшгульлек үзәкләрен искә төшерә. Алар эшсезләрне эш бирүчеләр белән тоташтыручы күпер кебек. Кичә Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында узган ел иң яхшы эшләгән мәшгульлек үзәген ачыкладылар. Бәйге ике турда үткәрелгән, икенче турга 12 район узган. Җиңүче район исеме соңрак билгеле булачак.**

Әлеге үзәкләр 26 ел элек барлыкка килгән. Министр Эльмира Зарипова әйтүенчә, шул дәвердә аларга төрле гозер-үтенеч белән 3,5 миллион кеше мөрәҗәгать иткән. 2,5 миллион кешене эшкә урнаштырганнар. Соңгы елларда балалар арасында да каникул чорында акча эшләп алырга теләүчеләр арта. Аларны да вакытлыча эшле итү мөмкинлекләрен эзлиләр. 6 мең кешегә квота буенча эш тәкъдим ителгән. Арада физик мөмкинлекләре чиклеләр дә байтак. 43 меңнән артык кеше үз эшен ачкан һәм ул оешмаларда 10 меңләп яңа хезмәт урыны булдырылган. Эшсез калучыларны яңа һөнәргә укыту эше белән дә мәшгульлек үзәкләре шөгыльләнә.

Бәйгенең икенче этабына үтүчеләр соңгы еллардагы эшчәнлекләре турында сөйләде. Махсус альбомнан тыш, видеоязма да әзерләгәннәр. Чистай, Буа районнары мәшгульлек үзәге җитәкчеләре чыгышы, кызганыч, әллә ни кызыксыну уята алмады. Алардан эшсезләр армиясе һәм аларны эшле итү чаралары турында күбрәк ишетәсе килгән иде. Зәй районында 194 кеше эшсезлек буенча исәптә тора. “Районда ел саен яңа оешмалар барлыкка килә, быел да шуларга күз атабыз, – диде районның мәшгульлек үзәге җитәкчесе Екатерина Андреева. – Узган ел 53 кешене шулар аша эшле итә алдык. Озакламый агросәнәгать комплексы, “Заман” агропромпаркы төзелә. Аларга да эшче көчләр кирәк булачак”. Зәй районыннан меңнән артык кеше Чаллыга, Түбән Камага, Әлмәткә барып эшли. Көн саен иртән чыгып китәләр, өйләренә кич кенә кайтып керәләр. Екатерина Андреева әйтүенчә, район хакимияте белән берлектә кешене читкә җибәрмичә, үзләрендә эшле итү җаен карыйлар. Райондагы инвалидларны эшле итү буенча эшче төркем булдырылган. Узган ел 68 физик мөмкинлеге чикле кеше мөрәҗәгать иткән булса, аларның 47сенә эш табып биргәннәр. Инвалидларны эшкә алучы оешмаларга дәүләт субсидия бүлеп бирә.

Бу җәһәттән Азнакай районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәген үрнәк итеп

китерергә мөмкин. Үзәк директоры Лилия Гафиева чыгышыннан күренгәнчә, “Россиядә эш” порталы белән даими элемтәдә торалар. Шуның аша оешмаларга – эшчеләрне, эшчеләргә хезмәт урыннарын төрле төбәкләрдән табып бирәләр. Райондагы оешмалар үзләренә нинди һөнәр ияләре кирәк булачагын алдан ук хәбәр итеп куя. Токарьлар, инженерларга ихтыяҗ бер дә кимеми. Азнакай районында 2013 елдан башлап оешмалар саны өч тапкыр арткан. Элек алар 60-70 булса, хәзер 300гә якынлаша. Мәшгульлек үзәгенә “Нефтемаш” заводыннан гел мөрәҗәгать итәләр. Соңгы елларда модульле фельдшер-акушерлык пункты биналарын республика районнарыннан тыш, Кырымда да төзиләр. Шуңа күрә инженерларга кытлык сизелә. Инвалидларны ничек эшле итүләре белән дә кызыксындык. Районда хезмәткә яраклы 1 мең 265 инвалид яши икән. Аларның 27 проценты – 345 кеше эшли. Быел беренче кварталда 40лап кеше эшкә урнаша алган. Шәхси эшмәкәрләр, инвалидлар җәмгыятьләре үзләренә чакыра.  “Күптән түгел бер егетебез зәркән эшләнмәләре остаханәсенә урнашты, – ди Лилия Рафисовна. – Барып хәлен белеп кайттык. Эшмәкәр дә, егет тә уртак тел тапкан, икесе дә канәгать. Физик мөмкинлеге чикле кеше, өйдә утырганда, үзен кимсенгән кебек тоя. Эшкә урнашкач, танымаслык булып үзгәрәләр. Безнең бурыч – аларның мөмкинлекләреннән чыгып эш табып бирү”.

Мәшгульлек үзәге белгечләре инвалид балалар янына өйгә дә бара.  Аларның нинди һөнәрләргә сәләтле булуын ачыклый. Ул киләчәктә һөнәр сайлаганда кирәк булачак. Башка районнардагы кебек Азнакайда да табиблар, укытучылар җитми. Эш эзләүче хисапчылар, менеджерлар, сатучылар күп. Бу белгечләргә заявкалар гына бик юк. Эшче һөнәрләрдән чәчтарашлар, визажистлар, маникюр осталары кирәк. Узган ел 184 эшсез кешене укытып  кайтарганнар, 20се – декрет ялында утыручы әниләр. Табибларны, укытучыларны читтән дә чакыралар. Районда иллегә илле программасы эшли. Яшьләр югары уку йортына түләүле бүлеккә кергәндә, район хакимияте түләүнең яртысын үзе каплый, калганын ата-ана күтәрә. Укуны тәмамлаган белгеч районга кайтып, кимендә өч ел эшләргә тиеш була. Табибларны, укытучыларны, төзелеш тармагы, авыл хуҗалыгы белгечләрен шулай әзерли башлаганнар.